**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

“08” декабрь 2020 ел №427

Карар

2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 февралендәге “2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү” дәүләт программасын раслау турында”гы 73 нче карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апрелендә “Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында”гы 346 нчы номерлы карарын үтәү йөзеннән, һәм балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында Әтнә район башкарма комитеты карар бирә :

1. - Әтнә муниципаль районында 2021 нче елга балалар һәм яшьләрнең ял итү программасын кушымта № 1 нигезендә
р а с л а р г а;

2. Әтнә район башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна оешмасына (алга таба-мәгариф бүлеге) (Гарипов Л.Т.), яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә (Мөхәмәтшин И. Ф..), Әтнә район башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторына (Муртазина Г.К.), шулай ук ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әтнә районындагы социаль яклау бүлегенә (Галиева А.А.) түбәндәгеләрне б а ш к а р ы р г а:

- күзәтүчесез калган һәм сукбай балалар, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар белән эш һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиядә исәптә торучы балигъ булмаганнар өчен барлык типтагы сәламәтләндерү лагерьларында урыннар бүлеп бирү (КДН һәм ЗП);

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге күпчелек балалар өчен оештырылган ял шартларын тудыру;

- 14-18 яшьлек балигъ булмаган балаларны укудан тыш һәм каникул вакытларында эш бирүчеләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты хисабына вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

- «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе (Сабирова А. К.) белән берлектә Әтнә муниципаль районы территориясендә эшчәнлеген алып баручы предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, оешмаларда балигъ булмаган балаларны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

- сәламәтләндерү учреждениеләрендә һәм оешкан ял урыннарында балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген, хокук тәртибен, санитар-экологик һәм янгын куркынычсызлыгын, суда куркынычсызлык кагыйдәләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидемиологик чаралар комплексын эшләү һәм үткәрү;

- һәр смена ачылыр алдыннан сәламәтләндерү учреждениеләренең янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, санитар кагыйдәләргә туры килүен, хезмәткәрләрнең эш шартларын һәм хезмәтне саклауның торышын, ял итүчеләрнең куркынычсызлыгын тикшерү максатыннан, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасы җайланмаларының, кешеләргә янгын турында хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, беренчел янгын сүндерү чараларының барлыгына һәм аларның төзеклегенә, шулай ук персоналның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүенә аеруча игътибар итеп, комплекслы тикшерүләр оештыру;

- балаларның ялын оештыру оешмалары тарафыннан санитар кагыйдәләр үтәлешен һәм санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар уздыруны тиешле тәртиптә аккредитацияләнгән лабораторияләр белән лаборатор-инструменталь тикшеренүләр үткәрү турында килешүләр төзү юлы белән башкару;

-медицина документларында ялга кабул итеп алынган балалар турында мәгълүмат, йогышлы авыруларга каршы прививкаларның илкүләм календарьга туры китереп ясалуы, яшәү, тәрбия алу һәм уку урыннарында йогышлы авырулар белән бәйләнешләрнең булмавы, туберкулинодиагностика нәтиҗәләре, флюорография тикшерүе (15 яшьтән үсмерләр өчен), гельминтозларга һәм эчәк протозоозларга тикшерү, йогышлы тире авырулары буенча карау, шул исәптән педикулезны да тикшерү турында мәгълүматларның булуы;

- урман-техник чараларын үткәрү (түбән үсүче һәм коры агач ботакларын, куакларны кисү, вак урман үсентеләрен һәм үләнне чабу, балаларның ял итү оешмалары территориясеннән коры чыбык-чабык һәм чүп-чарны чыгару), лагерь тирәли 500 метр радиуста коры чыбык-чабык һәм чүп-чарны дератизация һәм талпанга каршы эшкәртүгә кадәр һәм ялны оештыру кампаниясе дәвамында кирәк булган саен чыгару;

- дератизация эшкәртүен барлык корылмаларга, шул исәптән файдаланылмый торганнарына да, ачык территорияләргә, балаларның ял итү оешмалары тирәсендә 500 метр радиуслы барьерга ял итү оешмалары ачылырга 35-40 көн һәм 7 көн кала, консервацияләү алдыннан, шулай ук сменалар арасында уздыру, һәр дератизация эшкәртүеннән соң 30 көн узгач, нәтиҗәлелекне тикшерү;

- вируслы талпан энцефалиты буенча эндемик территориядә урнашкан стационар ял итү оешмаларында балаларның ял итү оешмалары территорияләрен һәм алар тирәли 50 метрлы зонаны ачылуга 20-25 көн кала, шулай ук сменалар арасында талпанга каршы эшкәртү;

- ял оешмаларына эшкә урнашучы (эшләүче) затларны закон нигезендә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясында каралган педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә каршылыклар булу (булмау) буенча алдан тикшерүне оештыру;

- балаларны транспортта йөртүне Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 декабрендәге 1177 номерлы “Балалар төркемнәрен автобуслар белән

йөртү кагыйдәләрен раслау турында"гы карары белән расланган Балалар төркемен автобус белән йөртүне оештыру кагыйдәләре нигезендә башкару;

оештырырга:

- талпан энцефалитын, боррелиозны һәм бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау максатларында корылмаларны һәм биналарны (шул исәптән файдаланылмый торганнарын да) һәм территорияне профилактик дымлы дезинфекцияләү, дезинсекцияләү һәм дератизацияләүне шушы эшләрне башкарырга хокукы булган аккредитация узган оешмалар белән дәүләт (муниципаль) контрактлары (шартнамәләре) төзү юлы белән үткәрү;
- лагерьны ачу һәм ябу алдыннан аның тирәсендәге 500 метрлы зонага барьер дератизациясе, алдан энтомологик бәяләү уздырып, лагерь янындагы 50 метрдан да ким булмаган территорияне талпанга каршы (:акарицид) эшкәртү, эшкәртелгәнче һәм эшкәртүдән соң 30 көн узгач, дератизация эшкәртүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тоту;
- ял оешмалары җитәкчеләрен һәм педагогик составын хезмәтне саклау буенча янгын-техник минимум һәм барлык хезмәткәрләрнең гигиеник әзерлеге программалары буенча билгеләнгән тәртиптә укыту һәм аларның еллык аттестациясен үткәрү;
- эпидемик тимгелле тиф һәм педикулезны профилактикалау максатыннан, урын-җир кирәк- яракларын, җәймәләрен камераларда дезинфекцияләүне ял оешмалары ачылганчы, тиешле тәртиптә аккредитацияләнгән оешмалар белән килешүләр төзү юлы белән үткәрү;
- балаларны һәм яшьләрне, алар балалар һәм яшьләр өчен ял итү оешмаларында һәм юлда булган вакытта, бәхетсезлек очракларыннан ирекле рәвештә иминләштерүне гамәлгә ашыру;

балалар һәм яшьләрнең ял итү оешмаларында территорияне, җәмәгать тәртибен һәм иминлеген саклауны шәхси сак оешмалары коче белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә.

2. Мәгариф бүлегенә:

- гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы ятим балаларның мәктәп яны лагерьларында, хезмәт һәм ял лагерьларында ялларын оештырырга;
- гомуми белем бирү мәктәпләренең көндезге мәктәп яны лагерьларының, хезмәт һәм ял лагерьларының матди-техник базасын 2021 елның 25 маена әзерләп бетерергә;
- башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларын һәм студентларын балалар сәламәтләндерү учреждениеләрендә практика узу чорында эшкә җәлеп итәргә;
- ял итүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен сәламәтләндерү лагерьларына җибәрелгән мәгариф системасы хезмәткәрләренең төп эш урыны буенча уртача хезмәт хакын саклап калу.

4. Яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә (Мөхәмәтшин И. Ф.) тәэмин итәргә:

-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 17.12.2004 елгы "Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау" хакындагы 542 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә балага айлык пособие алучы булып торучы, уртача җан башына керемнәре Татарстан

Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрдәге балаларның ялын оештыру, шушы категориягә кергән балалар төркемнәрен формалаштыру буенча җаваплы башкаручыларны билгеләү,

- мәгариф бүлеге белән берлектә гомуми белем бирү мәктәпләре, балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге учреждениеләре базасында балалар мәйданчыклары эшен оештыру.

5. Олы Әтнә үзәк шифаханәсенә (Яруллин Э.Ш.) тәкъдим итәргә:

- 4 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге инвалид балалар, җан башына уртача керем яшәү минимумыннан түбән булган гаилә балаларын, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны, медицина күрсәткечләрен һәм ярамаганнарны исәпкә алып, "Балалар" һәм "Ана һәм Бала" юлламалары буенча шифаханә учреждениеләрендә дәвалауны оештырырга;

- учредитель гаризасы буенча «Чулпан» стационар сәламәтләндерү лагерын контракт нигезендә медицина кадрлары белән тәэмин итү;

- укудан буш һәм каникул вакытларныда вакытлыча эшкә урнашучы балигъ булмаган балаларның медицина тикшерүләрен узуын түләүсез тәэмин итәргә;

- балалар сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә җибәрелә торган персоналны сезонлы тикшерүләрне Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрының 12.04.2011 елгы "Мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина тикшерүләре үткәрелергә тиешле зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторларының һәм эшләренең исемлеген раслау турындагы" № 302 боерыгы таләпләренә һәм Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында авыр эшләрдә эшләүче хезмәткәрләрнең мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина тикшеренүләрен үткәрү тәртибенә туры китереп, 2019 елда Татарстан Республикасында балалары һәм яшьләренең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга бүлеп бирелә торган акчалар хисабына оештырырга;

- ял оешмаларына җибәрелгән персоналга, сезонлы тикшерү кысаларында, түләүсез флюорография тикшеренүләре уздырырга .

6. "Татмедиа" ААҖ филиалы "Әтнә таңы" газетасы редакциясенә (Мөхәммәтдҗанова Г. Р.) сәламәтләндерү лагерьлары, көндезге мәктәп лагерьлары, хезмәт һәм ял лагерьлары эшенең уңай тәҗрибәсен һәм бу өлкәдә иң актуаль проблемаларны яктыртуны тәкъдим итәргә.

7. Әтнә район башкарма комитетының "Мәдәният бүлеге" муниципаль казна оешмасына (Гәләутдинова Г. Р.):

- сәламәтләндерү лагерьларында күчмә китапханәләр эшен оештырырга;

- җәйге каникуллар вакытында Әтнә муниципаль районы музейларына балаларны җәлеп итү максатыннан районның белем бирү оешмалары белән элемтә урнаштырырга;

- сәламәтләндерү лагерьларында концертлар, дискотекалар, тематик кичәләр оештырырга.

8. РФның РТ буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Әтнә һәм Арча муниципаль районнары буенча районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә (Сафин Р.Р.)

җәйге сәламәтләндерү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен күзәтчелек итәргә тәкъдим итәргә.

9. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсенең Арча, Биектау, Әтнә районнарындагы территориаль бүлегенә тәкъдим итәргә:

- балалар өчен ял һәм сәламәтләндерү учреждениеләренең гамәлдәге санитар нормалар һәм кагыйдәләргә туры килүенә санитар-эпидемиологик экспертиза уздырырга;

- балалар сәламәтләндерү учреждениеләренә җибәрелгән персоналны гигиеник укыту һәм аларга профилактик медицина тикшерүләре уздыру, учреждениеләр ачылыр алдыннан аларга лаборатория-инструменталь тикшерүләр, шулай ук гельминтозларга тикшеренүләр (суалчан күкәйләренә, лямблия цисталарына тизәк анализы, энтеробиозга кыру), эчәк инфекцияләрен барлыкка китерүчеләргә тикшеренүләр, корсак тифы авыруына канны серологик тикшерүләр үткәрергә;

- җәйге чорда вакытлыча эшкә урнашуны рәсмиләштергәндә балигъ булмаган балаларга медицина тикшерүләрен уздырырга;

- дәүләт йөкләмәсе кысаларында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм аның территориаль органы күрсәтмәләре нигезендә сәламәтләндерү оешмасы ачылыр алдыннан дератизация һәм акарицид эшкәртүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тотарга.

10. Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлегенә (Минһаҗев Л. А.) Әтнә муниципаль районы территориясендәге сәламәтләндерү лагерьларында җәмәгать тәртибен һәм иминлекне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

11. Сәламәтләндерү лагерьлары башлыкларына балаларның ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру нәтиҗәләре турында 2021 елның июнь аеннан сентябрь аена кадәр һәр айның 1 числосыннан соңга калмыйча яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә , мәгариф бүлегенә оператив мәгълүмат биреп барырга.

12. Предприятие, учреждение, барлык милек формасындагы оешма җитәкчеләренә җәйге каникулларда эшләүче балигъ булмаган балалар өчен имин хезмәт шартлары булдырырга һәм балигъ булмаганнарның хезмәтен файдалану турындагы законнарның үтәлешен тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

13. Әтнә муниципаль районы финанс-бюджет палатасына (Гимадиев Ф.И):

- әлеге карар белән расланган программаны Әтнә муниципаль районы 2021 елгы бюджетында сәламәтләндерү кампаниясен оештыру чараларын финанслау өчен каралган акчалар хисабына финансларга;

- программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тотарга.

14. Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының «Әтнә муниципаль районында 2020 елда балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру турында "2020 елның 12 мартындагы № 96 карарын 2021 елның 1 нче гыйнварыннан үз көчен югалта дип санарга.

15. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Каюмов А.Ф.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Башкарма комитетының “Әтнә муниципаль
районында 2021 елда балалар һәм яшьләрнең ялын
һәм сәламәтләндерүен оештыру турында”гы
08.12.2020 елдагы № 427
карары белән расланган

# 2021 ЕЛГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУ ПРОГРАММАСЫ

1. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2021 елга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм мәшгульлеген оештыру программасы (алга таба-Программа) |
| Муниципаль заказчы | ТР Әтнә район башкарма комитеты |
| Программаның төп Эшләүчесе | ТР Әтнә районы Башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" МКУ |
| Программаның төп башкаручылары | Әтнә районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>Әтнә районы Башкарма комитетының "мәгариф бүлеге" МКУ;<br>ТР Әтнә районы ЦЗН ДКУ;<br>"Әтнә үзәк район хастаханәсе" ДАСУ»;<br>Әтнә районы Башкарма комитетының "мәдәният бүлеге" МКУ;<br>Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек һәм контроль идарәсе Арча һәм Әтнә муниципаль районнары буенча районара ОНД;<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлекчәсе;<br>ТР буенча Роспотребнадзор Идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнары территориаль бүлеге. |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Балаларны яклау, балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру, аларның мәшгульлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру;<br>балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген тәэмин итү өчен шартлар тудыру;<br>тормыш эшчәнлеген яхшырту һәм имин булмаган балалар проблемаларын хәл итү;<br>балалар һәм яшьләрнең, балалар һәм яшьләр туризмы һәм спортның төрле ял, сәламәтләндерү һәм мәшгульлекләрен үстерү;<br>балалар һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү инфраструктурасын саклау һәм ныгыту;<br>балалар авыруын һәм инвалидлык профилактикасы;<br>балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2021 ел |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Иҗади яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен шәһәр яны лагерьларында профильле сменалар оештыру.<br>2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге яллары белән мәгариф оешмасы тарафыннан оештырылган лагерьларда сменалар оештыру. |

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2021 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 2350,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан ял һәм сәламәтләндерүне оештыруга субсидияләр-2326,8 мең сум; ата-аналар акчасы-23,5 мең сум. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларны ял һәм сәламәтләндерүнең төрле формалары белән 50 процент дәрәҗәсендә тәэмин итү. |

2. ӘЛЕГЕ ПРОГРАММА КЫСАЛАРЫНДА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ КҮЛӘМНӘРЕНЕҢ РАСЛАНГАН НОРМАТИВЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР

| Чаралар исеме | Үткәрү вакыты | Кеше саны | Оешма өчен җаваплы (башкаручы) |
|---|---|---|---|
| Иҗади сәләтле яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен профильле сменалар оештыру | апрель - декабрь | 40 | Әтнә районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, "Мәгариф бүлеге" МКУ |
| Мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре иҗат коллективларының балалар сәламәтләндерү лагерьларына концерт программалары белән чыгуы | апрель - сентябрь | 230 | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы мәдәният бүлеге |
| Балаларны савыктыру оешмаларын медицина кадрлары белән тәэмин итү | апрель - август | 2 | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Әтнә үзәк хастаханәсе |
| Балалар сәламәтләндерү лагерьларында фестивальләр, укыту-тренировка җыеннары үткәрү. | март - декабрь | 6 | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, “Мәгариф бүлеге” МКУ |
| Балалар һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү буенча физик культура һәм спорт учреждениеләре белән уртак эшне оештыру | июнь - август | 10 | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты |
| Балигъ булмаганнарның (мәктәп укучыларының) җәйге каникуллар чорында иҗтимагый-файдалы эшләр белән вакытлыча мәшгульлеген тәэмин итү | июнь - август | 15 | Әтнә районы ЦЗН ДКУ |
| Көндезге лагерьларда балалар белән эшләү өчен кадрлар әзерләү | июнь - август | 12 | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» МКУ |
| Көндезге лагерьларда гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучы балаларның ялын оештыру, | июнь - декабрь | 460 | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» МКУ |
| Вакытлыча эшкә урнашуны рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарга профилактик медицина тикшерүләре үткәрүне тәэмин итү | ел дәвамында | 113 | Татарстан Республикасының Әтнә район үзәк хастаханәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны, караучысызлыкны һәм җинаятьчелекне кисәтү максатыннан 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан буш вакытларында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | ел дәвамында | 113 | Әтнә районы ЦЗН ДКУ |
| Авыр тормыш хәлендә булган яшьләрне эшкә урнаштыру | ел дәвамында | 2 | Әтнә районы ЦЗН ДКУ |

3. ИҖАДИ ЯКТАН СӘЛӘТЛЕ ЯКИ СОЦИАЛЬ АКТИВ БАЛАЛАР ҺӘМ ВОЛОНТЕРЛАР, БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘР ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕ АКТИВЫ ӘГЪЗАЛАРЫ, ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘНҮЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ПАЛАТКА ТИБЫНДАГЫ ЛАГЕРЬЛАРДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Палатка тибындагы лагерь исеме (оештыручы) | Үткәрү территориясе | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр **мең сум. | Ата-аналар взносы **мең сум. | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет), мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| Бер балага туклану суммасы – 00 сум | | | | | | | |

4. ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ КӨНДЕЗГЕ ЯЛЛАРЫ БЕЛӘН МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ ТАРАФЫННАН ОЕШТЫРЫЛГАН ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Кешеләр саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** мең сум. | Ата-аналар взносы **мең сум | Башка акчалар (предприятиеләр, җирле бюджет) мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| МБОУ «Большеатнинская СОШ» | башл. мәктәп | 100 | 21 | 3800,0 | 323,0 | 57,0 | - |
| МБОУ «Коморгузинская СОШ» | башл. сыйныфлар | 30 | 21 | 3800,0 | 96,9 | 17,1 | |
| МБОУ «Берескинская СОШ» | башл. сыйныфлар | 30 | 21 | 3800,0 | 96,9 | 17,1 | |
| МБОУ «Березинская ООШ» | башл. сыйныфлар | 20 | 21 | 3800,0 | 64,6 | 11,4 | |
| МБОУ «Кушарская ООШ» | башл. сыйныфлар | 20 | 21 | 3800,0 | 64,6 | 11,4 | |
| барысы | | **200** | | | **646,0** | **114,0** | |
| Бер балага туклану суммасы – 3229,80 сум, мәдәни хезмәт күрсәтүгә – 228,00 сум, хуҗалык һәм канцелярия кирәк-яракларына – 342,20 сум. | | | | | | | |
| Калган чорда (көз) | | | | | | | |
| МБОУ «Большеатнинская СОШ» | башл. мәктәп | 100 | 7 | 1266,50 | 107,75 | 19,0 | - |
| МБОУ «Коморгузинская СОШ» | башл. сыйныфлар | 30 | 7 | 1266,50 | 32,3 | 5,7 | |
| МБОУ «Берескинская СОШ» | башл. сыйныфлар | 30 | 7 | 1266,50 | 32,3 | 5,7 | |
| МБОУ «Березинская ООШ» | башл. сыйныфлар | 20 | 7 | 1266,50 | 21,5 | 3,8 | |
| МБОУ «Кушарская ООШ» | башл. сыйныфлар | 20 | 7 | 1266,50 | 21,5 | 3,8 | |
| барысы | | **200** | | | 215,0 | 38,0 | |
| Бер балага туклану суммасы – 1076,60 сум, мәдәни хезмәт күрсәтүгә – 76,00 сум, хуҗалык һәм канцелярия кирәк-яракларына – 113,90 сум. | | | | | | | |
| Җәйге чорда хезмәт һәм ял лагере) | | | | | | | |
| МБОУ «Большеатнинская СОШ» | башл. мәктәп | 30 | 18 | 3256,67 | 97,7 | - | - |
| МБОУ «Коморгузинская СОШ» | башл. сыйныфлар | 15 | 18 | 3256,67 | 48,85 | | |
| МБОУ «Берескинская СОШ» | башл. сыйныфлар | 15 | 18 | 3256,67 | 48,85 | | |
| МБОУ «Березинская ООШ» | башл. сыйныфлар | 0 | 0 | | | | |
| МБОУ «Кушарская ООШ» | башл. сыйныфлар | 0 | 0 | | | | |
| барысы | | **60** | | | 195,4 | | |
| Бер балага туклану суммасы – 2768,40 сум, мәдәни хезмәт күрсәтүгә – 195,40 сум, хуҗалык һәм канцелярия кирәк-яракларына – 292,87 сум. | | | | | | | |

5. МУНИЦИПАЛЬ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ БАЛАЛАРЫ ҺӘМ КОММЕРЦИЯЛЕ ҺӘМ КОММЕРЦИЯЛЕ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАР ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН ШӘҺӘР ЯНЫ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ (ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРДӘН ТЫШ)

| Шәһәр читендәге лагерь исеме | Үткәрү территориясе | Балансста тотучының исеме | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** мең сум. | Ата-аналар взносы **мең сум | Башка акчалар (предприятиеләр, җирле бюджет) мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль бирем нигезендә | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

6. ШӘҺӘР ЯНЫ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Шәһәр читендәге лагерь исеме | Үткәрү территориясе | Балансста тотучының исеме | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** мең сум. | Ата-аналар взносы **мең сум | Башка акчалар (предприятиеләр, җирле бюджет) мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| В соответствии с муниципальным заданием | | | | | | | | |
| П/лагерь «Чулпан» | Лес Каенсар | Атнинский районный исполнительный комитет | 100 | 18 | 15248,0 | 1293,6 | 228,2 | |
| Калган чорда | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

7. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫ АКЧАЛАРЫННАН БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН, АЛАРНЫ САВЫКТЫРУНЫ ҺӘМ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ ОЕШТЫРУГА СУБСИДИЯЛӘР

| Күрсәткеч исеме | Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидияләр суммасы, мең сум. |
|---|---|
| Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне тәэмин итүгә дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең һәм хуҗалык итүче субъектларның (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) хезмәткәрләренең балалары арасыннан бер баласына финанс чыгымнары нормативы | - |